**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ИЛДЕРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

№11 03.04.2015 ел

Иске Илдерәк авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү һәм үткәрү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 24.03.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында», «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге Советы карары:

1. Иске Илдерәк авыл җирлеге Советы инициативасын хупларга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2015 елның 24 маенда якшәмбе көнне 7.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2015 елда Иске Илдерәк авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән, шулай ук теркәлмәгән, әмма Иске Илдерәк авыл җирлеге территориясендә яшәүче яки милеккә ия булган һәр кешедән, 1 һәм 2 гр Инвалидлар һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым чараларын кертүгә ,алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергщ ризамы?:

Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

**Кабер урыннарын тәртиптә тоту:**

Чуваш Енорускино авылындагы зиратны ремонтлау 58,4 мең сум;

- Илеш авылында зиратны ремонтлау-15 мең сум;

– Яңа Илдерәк авылында зиратны ремонтлау-22,2 мең сум;

**Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- Ленин урамы буенча Иске Илдерәк авылында вак таш белән капланган юлны ремонтлау-82,8 мең сум;

**Территорияләрне төзекләндерүне оештыру торак пунктлар чикләрендә:**

- Тарханка авылындагы чишмәне ремонтлау-21,6 мең сум;

РИЗА КАРШЫ».

3.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге территориясе чикләрендә референдум даирәсен билгеләргә.

4.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге башкарма комитетына 18 яшькә җиткән сайлаучылар исемлеген төзергә һәм Иске Илдерәк авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләренә раслау өчен тапшырырга.

5.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләренә гамәлдәге законнарга ярашлы рәвештә Иске Илдерәк авыл җирлеге территориясендә референдум үткәрүне оештырырга.
6.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә:

- ТР, Аксубай муниципаль районы, Иске Илдерәк авылы, Совет ур., 13;
- ТР, Аксубай муниципаль районы, Яңа Илдерәк авылы, Үзәк урам, 7 нче йорт;
- ТР, Аксубай муниципаль районы, Чуваш Енорускино авылы, Мәктәп урамы, 18 йорт;
- ТР, Аксубай муниципаль районы, Тарханка авылы, Көнбатыш урамы, 16 йорт;
- ТР, Аксубай муниципаль районы, Илеш авылы, Көнбатыш урамы, 20 йорт;

һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында.

Иске Илдерәк авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе: В.К. Альметкин